# 2023-2024 нче уку елының
# беренче яртыеллыгы нәтиҗәләре

2023-2024 нче уку елында педагогик профильле гимназия сыйныфларында барлыгы 58 укучы белем ала.

Бу уку елы Федераль белем бирү программасына күчү белән башланды. ФОП дип әйтәбез инде. Шуңа бәйле рәвештә 7,8,9 нчы сыйныфларда яңа фән – Вероятность и статистика фәне керә башлады. Моннан тыш өч сыйныфта да “Мөһим әйберләр турында сөйләшү”, “Россия – минем горизонт” класс сәгатьләре дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә үткәрелә.

**7 нче сыйныфның** класс җитәкчесе – Шиһабеддинова Гөлия Хәйдаровна. Беренче чирек башына 7 нче сыйныфта барлыгы 16 укучы. Икенче чирек ахырында ике укучы кире мәктәпкә кайтты. Шулай итеп, укучылар саны 14 булды. Аларның өчесе – Биектау районыннан, тулай торакта торалар. Ике укучы Арча районы авылларыннан килеп йөриләр. Калган укучылар (9 укучы – 64%) Арчаның үзеннән.

Беренче чиректә дүрт һәм бишле билгеләренә укучылар: Галимова Зәринә, Галиахметова Айсинә, Гафиятуллина Эвелина, Сагдиева Эвелина. Бер яки ике өчле белән калучылар: Аскарова Мәликә (вероятность и статистика), Ибрагимова Лилия (физика), Сафаргалиева Динә (вероятность и статистика, физика). Шулай итеп, өлгереш – 100 %, укуның сыйфаты 25 %ны тәшкил итте. Калдырылган дәресләр саны – 316 дәрес.

Икенче чирекне Галимова Зәринә, Галиахметова Айсинә, Гафиятуллина Эвелина, Сагдиева Эвелина, Яруллина Әминә дүртле һәм бишле билгеләренә тәмамлады. Бер яки ике өчле белән калучылар: Аскарова Мәликә (геометрия, физика), Ибрагимова Лилия (русский язык), Петрова Азалия (алгебра, вероятность и статистика), Сафаргалиева Динә (геометрия). Шулай итеп, өлгереш – 100 %, укуның сыйфаты 36 %ны тәшкил итте.

Калдырылган дәресләр саны – 740 дәрес. Административ-контроль эшләр график буенча алып барыла. Аларның нәтиҗәләрен (1 нче яртыеллык өчен):

7 класс

| № | Предмет | Успеваемость | Качество |
|---|---|---|---|
| 1. | География | 81% | 68% |
| 2. | Татарский язык | 95% | 49% |
| 3. | Алгебра | 85% | 23% |
| 4. | Геометрия | 73% | 53 % |
| 5. | Английский язык | 100% | 50% |

Дәрестән тыш вакытта, укучылар төрле түгәрәкләргә йөриләр: йөзү, туризм, шахмат һәм шашка түгәрәкләренә йөриләр. Укучылар дәрестән тыш төрле чараларда катнашалар. 7 нче сыйныф укучылары Арча боз сараена, гимназистлар рәтенә алу чарасында, көллияттә булган төрле акцияләрдә катнашалар. Өч сыйныфта макулатура җыюда, көллият территориясен җыештыруда, чаңгы ярышларында катнаштылар.

8 нче сыйныфның класс җитәкчесе  Яруллина Гөлназ Азатовна. Беренче чирек башында 23 кеше, өченче чиректә тагын бер укучы өстәлде, бер укучы семейное обучениега күчте. Бүгенге көндә 23 укучы белем ала. Ике укучы – Биектау районыннан, тулай торакта торалар.

1 нче чирек нәтиҗәләренә килгәндә, чирек ахырында дүрт һәм бишле билгеләренә тәмамлаучылар – Рамазанова Риана, Газизова Мәдинә, Хаҗиева Зәринә, Гыйләҗева Зәлинә, Вагыйзов Булат, Кәримов Алмаз, Вәлиева Язилә, Сәйфетдинова Рисәлә.  Бер яки ике өчле белән генә калучылар: Бариев Адель (алгебра, геометрия), Ибатуллина Карина (геометрия, вероятность и статистика), Ибраһимова Алия (вероятность и статистика), Мортазина Азалия (геометрия), Рамазанова Әмирә (алгебра, геометрия), Тремасова Агата (геометрия), Шаһидуллин Ислам (геометрия), Шәрифуллина Динә (геометрия).  Шулай итеп, өлгереш 100 %ны, уку сыйфаты – 35 % ны тәшкил итте. Калдырылган дәресләр саны – 310 дәрес.

2 нче чирекне дүрт һәм бишле билгеләренә тәмамлаучылар: Рамазанова Риана, Газизова Мәдинә, Хаҗиева Зәринә, Гыйләҗева Зәлинә, Вагыйзов Булат, Кәримов Алмаз, Вәлиева Язилә, Ибатуллина Карина, Ибрагимова Алия, Тремасова Агата, Шагидуллин Ислам. Бер яки ике өчле белән генә калучылар: Рамазанова Әмирә (алгебра, геометрия), Сәйфетдинова Рисәлә (алгебра).

Шулай итеп, өлгереш 100 %ны, уку сыйфаты – 47 % ны тәшкил итте. Калдырылган дәресләр саны – 387 дәрес. Административ-контроль эшләр график буенча алып барыла. Аларның нәтиҗәләре: (1 нче яртыеллык өчен)

8 класс

| № | Предмет | Успеваемость | Качество |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарский язык | 100% | 59% |
| 2. | Татарская литература | 100% | 40% |
| 3. | Алгебра | 88% | 24 % |
| 4. | Информатика | 90% | 45% |

Дәрестән тыш вакытта, укучылар төрле түгәрәкләргә йөриләр: йөзү, ату буенча түгәрәк, рәсем түгәрәге, агач белән эшләү, шахмат һәм шашка, фортепьяно түгәрәкләренә йөриләр.

9 нчы сыйныфның класс җитәкчесе – Гыйләҗева Алия Фәнәвил кызы. Уку елы башында 20 укучы, 2 нче чиректән 21 укучы. Аларның икесе – Әтнә районыннан, икесе – Биектау районыннан, берсе – Балтач районыннан.

Бишесе дә тулай торакта торалар. Бер укучы Божадан килеп йөри, калган укучылар Арчаның үзеннән.

1 нче чирекне 4 укучы (Абрарова Регина, Галимов Илюс, Муллагалиева Талия, Нәҗипова Адилә) дүртле һәм бишле билгеләренә тәмамлады. Бер генә өчле белән калучы укучылар: Богуатдинова Зөхрә (информатика), Валиуллина Лилия (вероятность и статистика), Тимергалиева Айзилә (вероятностҗ и статистика). Шулай итеп, беренче чиректә өлгереш – 100%, укуның сыйфаты – 20 %ны тәшкил итте. Калдырылган дәресләр саны – 260 дәрес.

2 нче чиректә дүртле һәм бишле билгеләренә генә тәмамлаучылар саны артты: Абрарова Регина, Галимов Илюс, Муллагалиева Талия, Нәҗипова Адилә**,** Гарифҗанов Инсаф, Тимергалиева Айзилә, Хаматуллина Азалия. Бер генә өчле белән геометрия фәненнән Гимранова Азалия калды.

Шулай итеп, икенче чиректә өлгереш – 100%, укуның сыйфаты – 33 %ны тәшкил итте. Калдырылган дәресләр саны – 200 дәрес. Административ-контроль эшләр график буенча алып барыла. Аларның нәтиҗәләре: (1 нче яртыеллык өчен)

9 класс

| № | Предмет | Успеваемость | Качество |
|---|---|---|---|
| 1. | Татарская литература | 100% | 92% |
| 2. | Алгебра | 95% | 47 % |
| 3. | Геометрия | 73% | 55% |
| 4. | Информатика | 85% | 23% |
| 5. | Английский язык | 100% | 76% |

Дәрестән тыш вакытта, укучылар төрле түгәрәкләргә йөриләр: йөзү, каратэ, туризм, бадминтон, түгәрәкләренә йөриләр. 9 нчы сыйныф “Акыллы бала” түгәрәгенә йөрүче балалар өчен Яңа ел тамашасы уздыруда, педагогик этика дәресе кысаларында үзләрен тәрбияче, укытучы ролендә сынап карадылар. Шулай ук Йошкар-Ола, Казан шәһәренә экскурсиядә булдылар, төрле тарихи урыннар белән таныштылар.

14 нче декабрь көнне 9 нчы сыйныф укучылары шәхси проект эшләрен якладылар. Уку елы дәвамында укучылар үзләренең фәнни җитәкчеләре белән бергә тикшеренүләр, тәҗрибәләр үткәрделәр, актуаль мәсьәләләрне тикшерделәр. Яклауга тәкъдим ителгән проектлар арасында социаль һәм тикшеренү проектлары да бар иде.

Проектлар төрле уку дисциплиналары буенча язылган: татар әдәбияты, татар теле, рус теле, рус әдәбияты, математика, биология, химия, җәмгыять белеме, тарих, тормыш иминлеге нигезләре, физик тәрбия һ.б.

Яклау презентацияләр һәм укучыларның сайланган тема буенча үз эшләрен күрсәтү белән үрелеп барды. Проект эшләре җитәкчеләренә зур рәхмәт

белдерәсем килә. Бик кызыклы проект эшләре бар иде, укучыларның күбесе “5” ле билгесе белән бәяләнде.

Төп дәүләт имтиханына (ОГЭга) әзерлек уку елы башыннан алып барыла. Рус теле һәм математикадан имтихан бирү һәр укучы өчен мәҗбүри. Ай саен диярлек бу фәннәрдән пробный сынау эшләп карыйлар. Район күләмендә дә язгы каникул вакытында бу фәннәрдән ОГЭ үткәреләчәк.

Укучылар моннан тыш ике фәннән сайлап алу имтиханында катнашалар. Бу уку елында, география, информатика, биология, инглиз теле, җәмгыять белеме, физика фәннәрен сайлап алдылар. Шунысы куанычлы, татар теле фәненнән дә имтихан сайлаучы 5 укучы бар. Консультацияләр графигы төзелде, барлык фәннәрдән дә дәрестән тыш вакытта консультацияләр үткәрелә.